ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Нурлат районы Покровский поселогын бетерү турында һәм «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 161-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Нурлат районы Покровский поселогын бетерү турында һәм «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 161-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 554-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Нурлат районы Покровский поселогын бетерү турында һәм «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Нурлат районы Покровский поселогын бетерергә.

**2 статья**


«Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 11 (II өлеш); 2014, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 76 (I өлеш) ); 2026, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның унҗиденче абзацында «, Покровский поселогы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нурлат муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрең билгеләү һәм
аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

«Нурлат муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче
муниципаль берәмлекләрнең чикләре
**карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- 12 - тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш
чикләре тасвирламасы

| | | |
|---|---|---|
| 1(1) | - 15(30) | - Әлки муниципаль районы |
| 15(30) | - 16(29) | - Алексеевск муниципаль районы |
| 16(29) | - 33(28) | - Аксубай муниципаль районы |
| 33(28) | - 34(27) | - Чирмешән муниципаль районы |
| 34(27) | - 1(1) | - Самара, Ульяновск өлкәләре |

«Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Нурлат шәһәре |
| 2 | Әмзә авыл җирлеге |
| 3 | Андреевка авыл җирлеге |
| 4 | Әхмәт авыл җирлеге |
| 5 | Биккол авыл җирлеге |
| 6 | Биләркүл авыл җирлеге |
| 7 | Богдашкино авыл җирлеге |
| 8 | Киекле авыл җирлеге |
| 9 | Гәйтән авыл җирлеге |
| 10 | Егоркино авыл җирлеге |
| 11 | Ялаур авыл җирлеге |
| 12 | Заречный авыл җирлеге |
| 13 | Кычытканлы авыл җирлеге |
| 14 | Колбай-Мораса авыл җирлеге |
| 15 | Мамык авыл җирлеге |
| 16 | Яңа Иглай авыл җирлеге |
| 17 | Яңа Тумба авыл җирлеге |
| 18 | Сәләнгеш авыл җирлеге |
| 19 | Урта Камышлы авыл җирлеге |
| 20 | Иске Әлмәт авыл җирлеге |
| 21 | Иске Чаллы авыл җирлеге |
| 22 | Би Күле авыл җирлеге |
| 23 | Тимерлек авыл җирлеге |
| 24 | Төрнәс авыл җирлеге |
| 25 | Фома авыл җирлеге |
| 26 | Чулпан авыл җирлеге |
| 27 | Якушкино авыл җирлеге |

».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Нурлат районы Покровский поселогын бетерү һәм «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Нурлат районы Покровский поселогын бетерү турында һәм «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы Нурлат районының Покровский поселогын бетерү максатыннан әзерләнде.

Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге территориясендә урнашкан Покровский поселогы торак пункт билгеләрен югалтты һәм алга таба аның үсеш перспективасы күренми.

Торак пункт территориясендә даими яшәүче халык, юл-транспорт инфраструктурасы, инженерлык коммуникацияләре, социаль, мәдәни, көнкүреш билгеләнешендәге объектлар, сәүдә, торак йортлар, төзелешләр, корылмалар, күчемсез мөлкәтнең башка объектлары юк.

«Татарстан Республикасының Техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖнең Нурлат филиалы белешмәләренә караганда, 2025 елның 25 февралендәге 32-09/118 номерлы белешмә нигезендә «БТИ» АҖнең Нурлат филиалы архив фондында Нурлат районы Яңа Тумба авыл җирлегенең Покровский поселогында урнашкан милек хокукын теркәү турындагы белешмәләр юк.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча Эчке эшләр бүлегенең 2025 елның 04 августындагы миграция мәсьәләләре буенча бүлекчәсе белешмәсе, архив мәгълүматлары нигезендә Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлегенең Покровский поселогы территориясендә яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлүчеләр юк.

Бердәм дәүләт реестрының 2026 елның 03 февралендәге 471-э 11 номерлы «Роскодастр» гавами-хокукый компаниясе тарафыннан тапшырылган күчемсез милек турындагы мәгълүматларына караганда, Нурлат районы Яңа Тумба авыл җирлегенең Покровский поселогы территориясендә индивидуаль торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары юк.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Покровский поселогы торак пункт билгеләрен югалткан, фактта тормыш бармый һәм алга таба үсеш перспективалары күренми.

Покровский поселогында кешеләрнең даими һәм өстенлекле яшәвен һәм тормыш эшчәнлеген яңарту өчен нигезләр юк.

Фикер алышу нәтиҗәләре буенча «Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкы торак пунктны бетерү инициативасын хуплады, законнарда каралган процедуралар үтәлде. Муниципаль районның һәм авыл җирлегенең вәкиллекле органнары тарафыннан тиешле карарлар кабул ителде.

Закон проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итмәячәк.

**«Татарстан Республикасы Нурлат районы Покровский поселогын бетерү турында һәм «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Нурлат районының Покровский поселогын бетерү һәм «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларны кабул итүне, үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны яисә үзгәртүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Нурлат районының Покровский поселогын бетерү турында һәм «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Нурлат районының Покровский поселогын бетерү турында һәм «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территориясе чикләрен һәм статусын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.